**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ДӨРЕШ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«17» май 2021 ел № 12/3

**«Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 нче декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Иске Дөреш авыл җирлегенең бюджеты турында» 6/2 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 нче декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Иске Дөреш авыл җирлегенең бюджеты турында» 6/2 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» мәгълүматны тыңлап, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 нче декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Иске Дөреш авыл җирлегенең бюджеты турында» 6/2 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 маддә 1 пункт 1 пунктчада «5845,68» саннарын «6116,45» саннарына алыштырырга,
- 1 маддә 1 пункт 2 пунктчада «5845,68» саннарын «6116,45» саннарына алыштырырга,

2. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иске Дөреш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, мондый карарлар җирле үзидарә органнарына, муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр һәм вәкаләтләр бирү белән бәйле рәвештә кабул ителгән очраклардан тыш".

3. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иске Дөреш авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүгә 2020 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2021 елда Иске Дөреш авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә".

4. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2020 елның 11 нче декабрендәге «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар планы чорына Иске Дөреш авыл җирлегенең бюджеты турында» 6/2 санлы карарының 1, 3, 7, 9, 11 кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе                                        Р.М. Дусадбеков